# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм "Балык Бистәсе муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 22 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

Балык Бистәсе муниципаль районы составына керүче "Биектау авыл җирлеге" һәм "Уракчы авыл җирлеге" муниципаль берәмлекләренең территорияләре чикләрен әлеге Законга кушымта нигезендә үзгәртергә.

**2 статья**

"Балык Бистәсе муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" 2005 елның 31 гыйнварындагы 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (III өлеш); 2008, № 11 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның егерме өченче абзацында "Николаевка авылы" сүзләрен "Наратлы, Николаевка авыллары" сүзләренә алмаштырырга;

2) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Балык Бистәсе муниципаль районы"
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү һәм
аларның статусы турында" Татарстан
Республикасы Законына
1 нче кушымта

# "Балык Бистәсе муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре **карта-схемасы**




Шартлы билгеләр

- муниципаль район чиге
- тоташу ноктасының тәртип саны
- жирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- жирлек үзәге

Муниципаль районның чиктәш чикләре тасвирламасы

| | |
|---|---|
| 52 (57) - 2 (56) | - Лаеш муниципаль районы |
| 2 (56) - 14 (55) | - Питрәч муниципаль районы |
| 14 (55) - 30 (54) | - Теләче муниципаль районы |
| 30 (54) - 31 (53) | - Саба муниципаль районы |
| 31 (53) - 60 (59) | - Мамадыш муниципаль районы |
| 60 (59) - 54 (58) | - Чистай муниципаль районы |
| 54 (58) - 52 (57) | - Алексеевск муниципаль районы |

"Балык Бистәсе муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы |
| 2 | Анатыш авыл җирлеге |
| 3 | Балыклы Чүкәй авыл җирлеге |
| 4 | Бәтке авыл җирлеге |
| 5 | Биектау авыл җирлеге |
| 6 | Олы Елга авыл җирлеге |
| 7 | Олы Кульга авыл җирлеге |
| 8 | Зур Мәшләк авыл җирлеге |
| 9 | Олы Әшнәк авыл җирлеге |
| 10 | Олы Солтан авыл җирлеге |
| 11 | Казак Чаллысы авыл җирлеге |
| 12 | Корноухово авыл җирлеге |
| 13 | Күгәрчен авыл җирлеге |
| 14 | Күки авыл җирлеге |
| 15 | Котлы Бөкәш авыл җирлеге |
| 16 | Масловка авыл җирлеге |
| 17 | Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге |
| 18 | Яңа Арыш авыл җирлеге |
| 19 | Полянка авыл җирлеге |
| 20 | Рус Әшнәге авыл җирлеге |
| 21 | Сорочьи Горы авыл җирлеге |
| 22 | Троицкий Урай авыл җирлеге |
| 23 | Уракчы авыл җирлеге |
| 24 | Шомарбаш авыл җирлеге |
| 25 | Югары Ырга авыл җирлеге |
| 26 | Шумбут авыл җирлеге |
| 27 | Шумково авыл җирлеге |
| 28 | Балтач авыл җирлеге"; |

3) 7 нче кушымтадагы бишенче абзацта ", Боровушка елгасын кисеп үтеп, 300 м төньяк-көнбатышка таба бара, алга таба уртак юнәлештә 1,9 км төньяк-көнчыгышка таба бу урманчылыктагы 52, 42 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап бара" сүзләрен "295 м төньяк-көнчыгышка таба әлеге автомобиль

юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк чиге буйлап уза, аны кисеп үтә һәм 620 м төньяк-көнчыгыш юнәлештә шушы урманчылыкның 42 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап бара" сүзләренә алмаштырырга;

4) 25 нче кушымтаның сигезенче абзацында ", Боровушка елгасын кисеп үтеп, 300 м төньяк-көнбатышка таба бара, шуннан соң уртак юнәлештә 1,9 км төньяк-көнчыгышка таба шушы урманчылыктагы 52, 42 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап бара" сүзләрен "295 м төньяк-көнчыгышка таба әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк чиге буйлап уза, аны кисеп үтә һәм 620 м төньяк-көнчыгыш юнәлештә шушы урманчылыкның 42 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап бара" сүзләренә алмаштырырга.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.


Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2010 елның 16 мае
№ 22-ТРЗ

«Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына кушымта

# Балык Бистәсе муниципаль районының аерым муниципаль берәмлекләре чикләрен үзгәртү карта-схемасы




М 1:120000

Шартлы билгеләр


район чиге


җирлекләрнең чикләре

торак пункт

Биектау авыл җирлегенең Уракчы авыл җирлеге территориясе составына кертелүче территориясе